ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дружба, д. 100а, с. Новый Кишит,
Арский муниципальный район, 422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Тынычлык урамы, 100а йорт,
Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

# КАРАР

9 октябрь 2017 ел № 11

Муниципаль берәмлек тарафыннан «Яңа Кишет авыл җирлеге» күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында.

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 июлендәге 880 номерлы карарына таянып, “Яңа Кишет авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кишет авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең түбәндәге административ регламентларын расларга:

1.1. Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1нче кушымта).

1.2. Адреслар бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта).

1.3. Васыять яисә ышанычнамә таныклыгы бирү буенча нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (3 нче кушымта).

1.4. Документлар күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (4 нче кушымта).

1.5. Гражданга социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль торак фондыннан торак урыны бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (5 нче кушымта).

1.6. Муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яисә өлешчә җирле әһәмияттәге юллар буенча уза торган маршрутлар буенча авыр йөкләр, зур габаритлы йөкләр ташуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (6 нчы кушымта).

2. «Яңа Кишет авыл җирлеге тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2016 елның 18 июлендәге 8 номерлы Яңа Кишет авыл җирлеге башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы Т.А.Арсланов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОКИШИТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609009820